# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Яңа Каенсар авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

27 ноябрь, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яңа Каенсар авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Важашур авыл җирлегенең Яңа Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, үзара салым суммасының 100 % ы күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация һәм контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Яңа Каенсар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*

*(Яңа Каенсар авылында елга аша Гагарин урамыннан Мәктәп урамына чыга торган юлны (күперне) төзү проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, төзү буенча башка эш төрләре);*

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен төзү, ремонтлау *(Яңа Каенсар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ясау, ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, күперләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау *(су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Яңа Каенсар авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү
*(Яңа Каенсар авылы чишмәләр төзү, ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Яңа Каенсар авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (*спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Яңа Каенсар авылы спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма кору, ремонтлау *(Яңа Каенсар авылында зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру).*

3. Әлеге карарны Важашур авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Важашур авыл җирлеге
башлыгы: П.Л. Иванов